ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 март 2026ел. № 2324

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы Карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 23 ноябрендәге 7629 номерлы, 2024 елның 12 июлендәге 4577 номерлы, 2025 елның 29 октябрендәге 8862 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 1.7 пункт өстәргә:

«1.7. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан, «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланыла.»;

2) 2.5.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктча өстәргә:

«7) mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендәге җир эшләренең чикләре (полигоны) яки түбәндәге ысулларның берсе белән җир эшләрен башкару урыны турында мәгълүматлар:

а) МСК 16 системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;

б) территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир участогының кадастр номеры;

в) картографик яки топографик нигездә эшләрне башкару урыны чикләренең схемасы.»;

3) 2.5.3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча өстәргә:

«5) mif/mid форматындагы атрибутив мәгълүматсыз вектор рәвешендәге җир эшләренең чикләре (полигоны) яки түбәндәге ысулларның берсе белән җир эшләрен башкару урыны турында мәгълүматлар:

а) МСК 16 системасында җир эшләре урнашкан урын контурының характерлы нокталары координаталары;

б) территориясендә җир эшләре башкарыла торган җир участогының кадастр номеры;

в) картографик яки топографик нигездә эшләрне башкару урыны чикләренең схемасы.»;

4) 2.5.5 пунктның 2 пунктчасын төшереп калдырырга;

5) 2.5.6 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасының гамәлдәге инженерлык челтәрләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына башкарма сурәттә чагылдырыла торган таләпләрне раслау турында» 2025 елның 16 сентябрендәге 1308/о номерлы Боерыгында бәян ителгән вектор моделе структурасына туры китереп тутырылган семантика белән, МСК-16 яки WGS 84 (EPSG:3857) координаталар системасында вектор форматындагы җир эшләре чикләрендә 1:500 масштабында һәм җир эшләре чикләрендә төшерелгән инженерлык челтәрләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының дөреслек һәм тулылык предметына ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар белән килештерелгән (инженерлык коммуникацияләрен төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда һәм инженерлык коммуникацияләренең урнашу урыны һәм/яки аларның характеристикалары үзгәргән очракта башка эшләрдә) башкарма сурәт.»;

6) 2.8.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча өстәргә:

«6) гариза бирүче Регламентның 2.5.1-2.5.6 пунктлары нигезендә мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар тапшырылмау яисә каршылыклы мәгълүматлар булган яки Регламентның 2.5.6 пунктының 2 пунктчасы таләпләренә туры килми торган документларны тапшыру.»;

7) 3.3.3.1 пунктта «электрон документлар әйләнеше системасы аша» сүзләрен «ГИСОГД системасы ярдәмендә» сүзләренә алмаштырырга;

8) 3.4.4 пунктта «электрон документлар әйләнеше системасы аша» сүзләрен «ГИСОГД системасы ярдәмендә» сүзләренә алмаштырырга;

9) 3.5.2.1 пунктта:

- җиденче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«җир эшләрен башкаруга ордерны ябу турында карар «ТР киңлекләрне планлаштыру институты» ДБУ белән килештерелергә тиеш;»;

- түбәндәге эчтәлектәге сигезенче абзац өстәргә:

«муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең әзерләнгән проектын билгеләнгән тәртиптә «ГИСОГД» системасы ярдәмендә килештерүгә җибәрә.»;

10) 3.5.2.2 пунктта «электрон документлар әйләнеше системасы аша» сүзләрен «ГИСОГД системасы ярдәмендә» сүзләренә алмаштырырга;

11) 3.5.3 пунктта «электрон документлар әйләнеше системасында» сүзләрен «ГИСОГД системасында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов